## ҖӘЙ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Без әти-әнием белән Изге Болгар җиренә сәяхәт кылдык. Ак мәчеттә, Икмәк музеенда булдык, хан каберлекләрен күрдек. Заманча архитектура үрнәкләренең бик килешле итеп борынгы стиль белән чиратлашуы матур тәэсир калдыра. Кара һәм Ак Пулат турында риваятьләр хәтеремә сеңеп калды. Бүгенге көндә дә анда казу-тикшеренү эшләре бара икән. Мин археологларның эшен бик кызыксынып күзәтеп тордым.Андагы тарихи-истәлекле урыннарда булу минем күңелемдә озак сакланыр. Киләчәктә тарихчы-археолог буласым бик килә. Ә бу хыялны тормышка ашыру өчен, тырышып укырга, күп белергә кирәк.

***Шәмсетдинов Айзат,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***



Җәй көнен мин ел саен түземсезлек белән көтеп алам, чөнки июль аенда минем туган көнем. Быел да бу көнне иртүк котлаулар кабул итә башладым. Башта дусларым белән бәйрәм иттек, уеннар уйнадык. Әнием төрле-төрле тәмле-татлы ризыклар пешереп сыйлады. Кич белән әби-бабайлар, туганнар котларга килде. Хөрмәтләп тә куйдылар соң үземне! Мин көн буе игътибар үзәгендә булдым. Ярый әле туган көн елга бер генә була, бөтенләй иркә малайга әйләнеп бетүең бар!

***Илһам Бариев,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***

Быел Казанда йөзү буенча дөнья чемпионаты үтте. Мин ачылу тантанасында катнашу бәхетенә ирештем. Тамаша искиткеч матур булды. Судагы шоу төрле төсләре белән бүген дә күз алдымда тора. Аннары синхрон йөзү ярышларын карадык. Казанга сәяхәт җәйнең иң истәлекле көннәренең берсе булды.

***Әхмәдиева Фәнисә,***
***5 нче б сыйныфы***




Без гаилә белән Ижау каласына кунакка бардык. Туганнар белән “Калашников музее”н карадык, зоопаркта булдык. Зоопарк бик бай. Монда нинди генә хайваннар, кошлар юк! Аюлар, дөя, пингвиннар, бөркетләр, тагын мин моңа кадәр гел белмәгән башка җәнлекләр күрдем. Маймыллар урнашкан читлек янынан бөтенләй китәсе килми, аларны көн буе күзәтсәң дә кызыгы бетмәс төсле. Әтием: “Читлеккә кереп китәсең бит инде, кызым”, - дип алар яныннан алып китте. Мин Ижау каласыннан матур тәэсирләр алып кайттым.

***Нуриева Диләрә,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***



Җәй җитсә, мин иркенгә чыгам. Рәхәтләнеп велосипедта йөрим, Ыкта су керәм, туйганчы дусларым белән аралашам. Ялларда әти белән кармакка балык тотабыз, учак янында сөйләшеп утырабыз. Кич белән хәлдән таеп йокыга китәсең, иртән туйганчы йоклыйсың – дөньяның бөтен рәхәте шул, дуслар. ВКда күпме телисең, шуның хәтле утырырга була, дәрес хәзерлисе дә юк. Менә шуның өчен дә җәйне яратам мин!

***Динар Гыйздәтов,***
***8а сыйныфы укучысы***

